**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5505**
**25.10.2019**

Башкарма комитетның аерым карарлары
үз көчен югалткан дип тану турында

«Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 июнендәге 151-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.21 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 6 сентябрендәге 5212 нче карары;

2) Башкарма комитетның «Акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 7 декабрендәге 7600 нче карары;

3) Башкарма комитетның «Акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 23 октябрендәге 6287 нче карары;

4) Башкарма комитетның «Акчалары күп фатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 5 апрелендәге 1746 нчы карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин